| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2020 г.Казань № 517

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 6 августында 6804 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф. Валиуллов

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 14 июлендәге 517 номерлы боерыгы белән расланган

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 639 номерлы «Ата-аналарның мәктәпкәчә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында балага күзәтеп һәм карап торган өчен түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 12.10.2015 ел № 730, 19.05.2016 ел № 278, 28.11.2016 ел № 668, 08.06.2017 ел № 349, 07.05.2018 ел № 350, 18.09.2018 ел № 858, 22.04.2019 ел № 290, 19.08.2019 ел № 635, 11.11.2019 ел № 978 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Ата-аналарның мәктәпкәчә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында балага күзәтеп һәм карап торган өчен түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Нигезләмә» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы «Ата-аналарның мәктәпкәчә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында балага күзәтеп һәм карап торган өчен түләвенең бер өлешенә компенсация турында» карары белән расланган Ата-аналарның мәктәпкәчә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында балага күзәтеп һәм карап торган өчен түләвенең бер өлешенә компенсация алу өчен мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасында «20 номерлы Тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы 3 пунктчада «63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.15 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «Федераль законның 151 статьясы» сүзләрен «210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.1 пунктчаның беренче абзацында «2013 елның 23 октябреннән соң Татарстан Республикасында туган балаларны» сүзләрен «балаларны – » сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2 пунктчаның икенче абзацында «2013 елның 23 октябренә кадәр Татарстан Республикасында туган балаларны» сүзләрен «балаларны – » сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2012 елның 20 июнендәге 445 номерлы «Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 04.09.2014 ел № 485, 07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 399, 08.06.2017 ел № 351, 07.05.2018 ел № 352, 18.09.2018 ел № 885, 07.05.2019 ел № 324, 14.11.2019 ел № 1011, 25.03.2020 ел № 193 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карарының 1 п.» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карары белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү кагыйдәләре (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы ундүртенче абзацта «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пунктындагы «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «ТР МК карары белән расланган 880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт

хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.1 пунктының икенче абзацында «2013 елның 23 октябреннән соң туган балалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.2 пунктының икенче абзацында «2013 елның 23 октябреннән соң туган балалар» сүзләрен төшереп калдырырга.